Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасының дәүләт
бурычы турында

1 статья. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасының дәүләт бурычы чыгарылган һәм түләнмәгән дәүләт заемнары һәм бурыч йөкләмәләре суммасыннан гыйбарәт.

Эчке һәм тышкы базардагы юридик һәм физик затлар Татарстан Республикасының дәүләт бурычы буенча заем бирүчеләр булып торалар.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты Татарстан Республикасының дәүләт бурычы буенча заемчы булып тора.

Татарстан Республикасының дәүләт бурычы үз эченә Татарстан Республикасының эчке дәүләт бурычын һәм Татарстан Республикасының тышкы дәүләт бурычын ала.

2. Татарстан Республикасының эчке дәүләт бурычы Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең юридик һәм физик затлары алдындагы бурыч йөкләмәләреннән гыйбарәт.

3. Татарстан Республикасының тышкы дәүләт бурычы Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының чит дәүләтләрдән, халыкара финанс оешмаларыннан, чит илләрнең коммерция банкларыннан һәм фирмаларыннан, физик затлардан закон билгеләгән тәртиптә алган бурыч йөкләмәләре буенча бурычлары суммасыннан гыйбарәт.

2 статья. Татарстан Республикасының дәүләт бурычы формалары һәм составы

1. Татарстан Республикасының дәүләт бурычы:

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты алган кредитлардан;

дәүләтнең кыйммәтле кәгазьләрен чыгару аша гамәлгә ашырылган дәүләт заемнарыннан;

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан гарантияләнгән башка бурыч йөкләмәләреннән торырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасының дәүләт бурычы узган еллар бурычларыннан һәм яңа җыелган бурычлардан тора.

3. Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләре кыска вакытка (1 елга кадәр), уртача вакытка (1 елдан 5 елга кадәр) һәм озак вакытка исәпләнгән (5 елдан 20 елда кадәр) булырга мөмкин.

Дәүләт облигацияләрен яисә башка кыйммәтле кәгазьләрне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты кушуы буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнгән эмиссия күләмнәре чикләрендә чыгара.

Процентлар дәүләт заемы шартнамәсе нигезендә түләнә. Дәүләт заемы шартнамәсендә процентлар күләме турындагы шартлар күрсәтелмәсә, ул заемчы бурыч суммасын яисә аның тиешле өлешен түләгән көнгә рефинанслауның банк проценты ставкасы белән законнар нигезендә билгеләнә.

4. Дәүләт бурычы составына кертелүче дәүләт заемнары заем бирүчегә заем алучыдан заемны әйләнешкә чыгару шартларында каралган вакытларда үзенә бирелгән заем өчен акча яисә башка мөлкәт алу, билгеләнгән процентлар алу хокукы яисә башка мөлкәти хокукларны таныклаучы дәүләт облигацияләре яки башка кыйммәтле кәгазьләр алу аша рәсмиләштерелә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан инвестиция программаларын финанслау өчен әйләнешкә законнар нигезендә максатлы дәүләт облигацияләре яисә башка кыйммәтле кәгазьләр чыгарылырга мөмкин. Әлеге заемнарның күләмнәре кирәкле инвестиция күләмнәре, аларның үзләрен аклау вакыты белән билгеләнә.

3 статья. Татарстан Республикасының дәүләт бурычын тәэмин итү

1. Татарстан Республикасының дәүләт бурычы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карамагында булган барлык активлар белән тәэмин ителә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты заем бирүчеләр алдындагы йөкләмәләрен үз вакытында һәм тулысынча үтәү чаралары күрә, моның өчен Татарстан Республикасының Республика бюджеты керемнәреннән, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карамагындагы активларны сатудан кергән акчаны да кертеп, кирәкле резервлар оештыра.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнарының бурыч йөкләмәләре өчен, алар Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан гарантияләнмәгән булса, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты җавап бирми.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең бурыч йөкләмәләре өчен, моңа эш хакын, пенсияләрне һәм башка бурыч йөкләмәләрен дә кертеп, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты җавап бирми.

4 статья. Татарстан Республикасы дәүләт бурычы белән идарә итү, аңа хезмәт күрсәтү һәм аның торышын тикшереп тору

1. Татарстан Республикасы тышкы дәүләт бурычының һәм Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының югары чикләрен билгеләү алдагы финанс елына Татарстан Республикасының Республика бюджетын раслаганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан аерым башкарыла.

2. Татарстан Республикасының дәүләт бурычы белән идарә итү, шул исәптән бурыч йөкләмәләре тәртибен, чыгару һәм урнаштыру шартларын билгеләү Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.

3. Татарстан Республикасының дәүләт бурычына, бурыч йөкләмәләрен урнаштыру, аларны каплау, алар буенча процентлар рәвешендәге керемнәрне түләү яки башкача хезмәт күрсәтү Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының дәүләт бурычы белән идарә итү һәм аңа хезмәт күрсәтү буенча чыгымнар Татарстан Республикасының Республика бюджеты акчалары хисабыннан гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасының дәүләт бурычы торышын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тикшереп тора.

5 статья. Татарстан Республикасының дәүләт бурычы турында мәгълүмат

1. Татарстан Республикасының дәүләт бурычы турында мәгълүматны матбугатта игълан итү, финанс елы йомгаклары буенча, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

Әлеге Законны матбугатта игълан иткән көннән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 22 мае
N 1181